СОВЕТ КУРКУЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
КЫРКУЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с. Кыркул

05.07.2022 № 31

**Алексеевск муниципаль районы Кыркул авыл җирлеге советының 07.04.2016 №31 нче «Кыркул авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгәдәгъ вакылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр, шулайук муниципаль берәмлектә муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакындагы» карарына үзгәрешләр кертү турында (19.11.2018 ел №98, 28.06.2021ел №20 дәге үзгәрешләр белән.)**

«Россия Федерациясенеңаерым закон актларынаүзгәрешләркертүтурында» 01.04.2022 ел, № 90-ФЗ Федераль закон кабул ителүгәбәйлерәвештә, «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турындаһәм Россия Федерациясенеңаерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыручаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указы нигезендә,

**Кыркул авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Кыркул авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Кыркул авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Алексеевск муниципаль районы Кыркул авыл җирлеге Советының 2016 елның 7 апрелендәге 31 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, 8 пунктның 3 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«3) үз чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын,

кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активларын, цифрлы валютаны хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр), әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганга кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән, алыш-биреш башкарылган алыш-биреш чыганакларыннан артып китсә.».

2.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыркул авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Кыркул авыл җирлеге башлыгы** **Е.А.Косова**

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «КУРКУЛЬСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
р 05-11124/13
СОВЕТ КУРКУЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ